| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.04.2016 г. Казань № под-773/16___

**«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «татарстан республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсы турында**

«2015-2016 уку елына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының эш планын раслау турында» 2015 елның 23 июлендәге под-8252/15 номерлы боерыгы белән расланган 2015-2016 уку елына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының эш планы нигезендә боерык бирәм:

1. 2016 елның II-IV кварталларында «Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсын үткәрергә.

3. Расларга (кушымта итеп бирелә):

«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсы турында нигезләмәне;

«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсының оештыру комитеты составын.

3.Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.Ф.Гатиятуллина) «Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсын үткәрү чыгымнарын Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җыелма бюджет сметасы акчалары хисабына түләргә.

4.Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф идарәсе органнарына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына һәм һөнәри мәгариф оешмаларына конкурста педагогик хезмәткәрләрнең актив катнашуын һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына заявкалар тапшыруын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 26 апрелендәге под-773/16 номерлы боерыгы белән расланган

# «МӘГАРИФТӘ ИННОВАЦИЯЛӘР» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӨЧЕН ИҢ ЯХШЫ ИЛЛЕ ИННОВАЦИОН ИДЕЯ» РЕСПУБЛИКА КОНКУРСЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә «Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү максатын, бурычларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны үткәрүнең максаты - Татарстан Республикасы педагогик бергәлегенең инновацион эшчәнлегенә этәргеч бирү.

1.3. Конкурсның бурычлары:

тәрбиячеләргә, педагогик хезмәткәрләргә, эшкуарларга мәгариф технологияләре өлкәсендә инновацион фәнни-тикшеренү эшчәнлеге өчен этәргеч бирү;

педагоглар бергәлеген фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә һәм инновацион иҗатка җәлеп итү;

мәгариф системасына тормышка ашырырдай технологияләрне гамәлгә кертүгә шартлар тудыру.

1.4. Конкурсны оештыручы булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

Конкурсның эш органы булып 13 кешедән гыйбарәт Конкурсның оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) тора. Оештыру комитетының персональ составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, конкурс эшләренщ экспертларның бәяләвен оештыру өчен «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен тауарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә экспертлар сайлап алуны хәл итүче һәм аларның эшен оештыручы оешманы (алга таба – Оешма) җәлеп итә.

1.5. Конкурс түбәндәге юнәлешләр (алга таба – юнәлеш) буенча үткәрелә:

мәктәпкәчә белем бирү;

башлангыч белем бирү, сәламәт тормыш рәвеше;

математика, физика, информатика;

филология һәм лингвистика;

экология, биология, химия;

тарих, география;

милли мәгариф;

өстәмә белем бирү һәм тәрбия;

урта һөнәри белем бирү;

югары һөнәри белем бирү.

1.6. Конкурс үткәрү сроклары, шартлары турында мәгълүмат әлеге Нигезләмә расланганнан соң ике айдан да соңга калмыйча Министрлыкның рәсми сайтына (http://mon.tatarstan.ru/rus/innovac–idei.htm) «Чаралар» бүлегенә урнаштырыла.

## 2.ХЕЗМӘТЛӘРНЕ ТӘКЪДИМ ИТҮ ҺӘМ РӘСМИЛӘШТЕРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. 2.1.Конкурста түбәндәгеләр катнаша ала (алга таба – Мөрәҗәгать итүче):
мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре;
гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре;
һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре;
өстәмә белем бирү һәм тәрбия оешмаларының педагогик хезмәткәрләре;
югары белем бирүче мәгариф оешмаларының профессор-укытучылары;
мәгарифтә инновацион проектларны тормышка ашыручы эшкуарлар.

2.2. Конкурста индивидуаль яки күмәк (катнашучылар теләгенә карап) катнашырга була. Күмәк катнашучылар составына мөрәҗәгать итүче һәм автордашлар (икедән артмаска тиеш) керә.

2.3. Конкурста катнашуга заявка түбәндәге документларны үз эченә ала:

2.3.1. Әлеге Нигезләмәгә 1нче кушымта нигезендә анкета-заявка.

2.3.2. Мөрәҗәгать итүче, Мөрәҗәгать итүче эшли торган оешма һәм автордашлар арасындагы мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә җайга салына.

2.3.3. Әлеге нигезләмәгә 2нче кушымта нигезендә, мөрәҗәгать итүчедән шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык.  Конкурска заявка авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык авторларның барысы тарафыннан бирелергә тиеш.

2.3.4. Проектны белем бирү практикасына кертүне яки кертү турында ниятләнүне раслаучы документлар (практикага кертү турында актлар, Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларыннан таныклыклар һ.б.).

2.4. Конкурста катнашуга заявкалар кәгазьдә (ике нөсхәдә) һәм электрон туплагычларда (Word форматында анкета-заявка, калган документлар – PDF форматында сканерланган) тапшырыла.

2.5. Конкурста катнашуга заявка рәсмиләштерү түбәндәге шартларны канәгатьләндерергә тиеш:

электрон туплагычта санлы форматта тапшырыла, заявканың кәгазьдәге нөсхәләренә кушып бирелә;

рәвеше (тәкъдим итү, фотосурәтләр, диаграммалар, графика, блок-схемалар һ.б.);

текстлы мәгълүматы:  шрифты – 14, Times New Roman, интервалы – 1,5;

эчтәлеге һәм күләме ягыннан мәгълүматларның җыйнак булуы (проект тасвирламасы белән заявка-анкета 10 биттән артмаска тиеш).

2.6. Анкета-заявкада проект тасвирламасы түбәндәге төп элементлардан торырга тиеш:
хезмәтнең максатлары һәм бурычлары;
кыскача эчтәлеге;
проектны тормышка ашыру өчен кирәкле ресурслар (кадрлар, финанс, башкалар) күләмен билгеләү;
төп нәтиҗәләр;
куллану өлкәсе.

2.7. Түбәндәге очракларда заявкалар Конкурста катнашуга кертелми:
әлеге Нигезләмәнең 2.2.-2.6 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән;
әлеге Нигезләмәнең 3.1.1 пунктында күрсәтелгән Конкурста катнашуга заявкалар тапшыру срогы үткәч килгән очракларда.

2.8. Мөрәҗәгать итүче Конкурста катнашуга заявка тапшырганда Конкурс үткәрү шартларына ризалыгын бирә һәм тапшырылган материалларның яшерен булып калуын таләп итми.

2.9. Конкурска алынган материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

## 3. КОНКУРСНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ

3.1. Конкурс түбәндәге срокларда өч этапта үткәрелә:

3.1.1. Беренче этабы (заявкалар җыю) әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына урнаштырылган көннән агымдагы елның 15 октябренә кадәр үткәрелә. Конкурсның беренче этабында Министрлык Конкурста катнашуга заявкаларны кабул итә һәм терки.

Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында, гомуми белем бирү оешмаларында, югары белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм һөнәри мәгариф оешмаларында әлеге Нигезләмәнең 1.5 пункты нигезендә Конкурста катнашучылар кандидатураларын һәм проектлар тематикасын билгеләү буенча әзерлек эше башкарыла, шуннан соң Конкурста катнашуга заявкалар булдырыла.

Конкурста катнашуга заявкалар җыю конкурста катнашучылар эшли торган муниципаль мәгариф оешмалары аша муниципаль мәгариф идарәсе органнары тарафыннан башкарыла. Җыелган заявкалар Министрлыкка җибәрелә.

Конкурста катнашучылар заявкалары мәгарифтә инновацион проектларны тормышка ашыра торган югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри мәгариф оешмалары, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары тарафыннан Министрлыкка мөстәкыйль рәвештә җибәрелә.

Оештыру комитеты, бу нигезләмәнең 2.7 пункты таләпләреннән чыгып, Конкурста катнашуга кертү мөмкинлеген билгеләү максатыннан, тапшырылган заявкаларны анализлый. Анализ ясау, бу максатта Оештыру комитеты составында булдырылган Оештыру комитетының эш төркеме утырышларында (заявкалар керүгә карап үткәрелә) башкарыла.

3.1.2. Икенче этабы быелның 16 октябреннән 30 ноябренә кадәр үткәрелә.

Оешма быелның 16 октябрендә Конкурста катнашуга кертелгән заявкаларны акт буенча Оештыру комитеты сәркатибеннән ала.

Тапшырылган заявкаларны бәяләү өчен Оешма тарафыннан җәлеп ителгән экспертлар (алга таба – Экспертлар советы) заявкаларга экспертиза үткәрә. Экспертлар советы составына 16 эксперт керә, аларны сайлап алу Министрлык тарафыннан эшләнгән һәм Оешманы сайлап алуда конкурс документлары составына кергән техник бирем нигезендә башкарыла (әлеге Нигезләмәнең 1.4 пункты).

Экспертлар советының составы һәм эшчәнлеге турында мәгълүмат үтә яшерен мәгълүмат булып тора (өченче затларга бирелми).

Конкурс әлеге Нигезләмәгә 3нче кушымта нигезендә конкурска сайлап алу критерийлары нигезендә үткәрелә.

Заявкаларга экспертиза ясау Экспертлар советы тарафыннан тикшерү юлы, шул исәптән плагиат билгеләренең булу-булмавын тикшерү, тапшырылган һәр хезмәтнең критерийларга туры килү-килмәвен бәяләү юлы белән башкарыла.

Экспертиза нәтиҗәләре буенча, әлеге нигезләмәнең 1.5 пункты нигезендә һәр юнәлеш буенча, Конкурста катнашучылар рейтингы булдырыла. Һәр юнәлеш буенча рейтингта беренче урынны алган мөрәҗәгать итүчеләр (10кеше) - Конкурста җиңүчеләр булып, икенче һәм өченче урынны алучылар призерлар булып таныла.

Экспертлар советының эш нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә; ул Оештыру комитетына Конкурсның икенче этабы тәмамланырга күп дигәндә сигез көн кала җибәрелә.

Экспертлар советы беркетмәсе Оештыру комитеты тарафыннан алынган көнне Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүче, Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, Оештыру комитетына апелляция бирергә хокуклы.

Апелляция, Министрлык сайтына Экспертлар советы беркетмәсе урнаштырылганнан соң өч эш көне эчендә, Оештыру комитеты рәисе исеменә ирекле формада язмача тапшырыла. Тапшырылган апелляцияләр ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында Оештыру комитеты әгъзаларына җибәрелә.

Оештыру комитеты әгъзалары апелляцияләр кабул итү срогы тәмамланганнан соң дүрт эш көне эчендә аларны карап тикшерә һәм күмәк фикер алышу үткәрә. Карар ачык тавыш бирү

юлы белән күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә һәм Оештыру комитеты әгъзаларының күпчелеге катнашкан очракта, легитим, дип таныла. Тавышлар бертигез булган очракта, Оештыру комитеты рәисенең тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты сәркатибе Конкурсның икенче этабы тәмамланырга күп дигәндә бер эш көне кала апелляцияләрне карап тикшерү нәтиҗәләрен гомумиләштерә һәм беркетмә төзи. Беркетмәдә Оештыру комитетының һәр әгъзасының фикере һәм гомуми нәтиҗә күрсәтелә:

апелляцияне инкарь итү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Беркетмә Оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре тарафыннан имзалана.

Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Оештыру комитеты карары ахыргы карар булып тора, яңадан карала алмый, карарга суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

3.1.3. Конкурсның өченче этабы быелның 1 декабреннән 31 декабренә кадәр үткәрелә.

Өченче этапта билгеләнгән тәртиптә Конкурс җиңүчеләре дип танылган ун кешегә диплом һәм 50000 мең сум күләмендә акча тантаналы төстә тапшырыла.

Министрлык тарафыннан «Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» Конкурсы йомгаклары турында» боерык чыгарыла, әлеге боерык имзаланганнан соң өч көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла. Конкурс призерлары боерык нигезендә Министрлык дипломнары белән бүләкләнә.

«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә
«Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея» республика конкурсы турында нигезләмәгә 1нче кушымта

«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә
«Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле инновацион идея»
КОНКУРСЫНДА КАТНАШУЧЫНЫҢ АНКЕТА-ЗАЯВКАСЫ

1 Проект атамасы: ________________________________________________________
2 Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.О*, эш урыны һәм вазыйфасы: ______________________________
________________________________________________________________________________
3. Элемтәгә керү өчен мәгълүмат (телефон, e-mail): ______________________________
4. Башка затлар – проект автордашлары турында мәгълүмат ____________________________
________________________________________________________________________________
5. Проект буенча мәкаләләрнең Scopus, Web of Science системасында цитата индексы белән халыкара журналларда дөнья күрүе, патентларга ия булу турында мәгълүматлар (мондый мәгълүматлар булганда):
____________________________________________________________
6. Юнәлеш (Конкурс турында Нигезләмәнең 1.6 пунктына туры китереп ):____________
________________________________________________________________________________

| |
|---|
| 7. Проектның кыскача аннотациясе (10 юлдан артмаска тиеш) |
| |
| 8. Проектның актуальлеге |
| |
| 9. Проектның тасвирламасы |
| |
| 10. Проектның яңалыгы |
| |
| 11. Проектның тормышка ашыруның агымдагы стадиясе |
| |
| 12. Проектның перспективадагы максатлары |
| |
| 13. Чыгымнарның җыелма күләме <*> |
| |

| 14. Проектның үз бәясен аклау срогы <*> |
| --- |
| |

--------------------------------

<*> Белешмә өчен күрсәтелә.

Конкурс турында Нигезләмәдә бәян ителгән конкурс үткәрү шартларына риза

___________________________________ ________________ ______________________

ФИО имза дата

«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә
«Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле
инновацион идея» республика конкурсы
турында нигезләмәгә 2нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык
(җиңүчеләр тарафыннан акчалата премияләр алу өчен тутырыла)

«___» _____________ 20___ ел

Мин, _______________________________, паспорт серия ______, номер_______,бирелгән «___» _____________ 20______ел _________________________________,түбәндәге адрес буенча теркәлгән: _________________________________________________________________, «Шәхси мәгълүматларны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге ФЗ-152 номерлы федераль законны үтәү кысаларында, Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына үземнең шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Министрлык Россия Федерациясе законнары таләпләреннән тыш, башка бернинди шартларда, бу килешүдә күрсәтелгән мәгълүматларны, минем ризалыктан башка гына, өченче затларга тапшырмаска тиеш. Шәхси мәгълүматлар яшерен мәгълүмат булып тора һәм Министрлык яки теләсә кайсы башка зат тарафыннан шәхси максатта файдаланыла алмый.

Министрлык тапшырылган шәхси мәгълүматларны рөхсәтсез файдаланудан саклау өчен кирәкле барлык чараларны күрә.

Бу Ризалык кысаларында шәхси мәгълүматларны саклау, тарату, куллану формасында шәхси мәгълүматларны эшкәртү законнар һәм башка норматив хокукый актларны үтәү нигезендә башкарыла.

Әлеге Ризалык катнашучының заявкасы белән конвертларны ачканнан соң яки конкурста катнашучының электрон заявкалары белән танышу мөмкинлеге булганнан соң 3 (өч) ел эчендә гамәлдә була. Әлеге срок тәмамлангач шәхси мәгълүматлар юкка чыгарылырга тиеш.

Ризалык Министрлык адресына гади язма рәвештә тиешле гариза җибәрү юлы белән шәхсән минем тарафтан кире соратып алынырга мөмкин.

_____________________/____________________/
Имза                                    ФИА

«Мәгарифтә инновацияләр» номинациясендә
«Татарстан Республикасы өчен иң яхшы илле
инновацион идея» республика конкурсы
турында нигезләмәгә 3нче кушымта

**БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ**

| Хезмәтләрне бәяләү критерийлары | Баллар | Критерийның зурлыгы | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|
| 1 критерий. Тәкъдим ителә торган проектта (хезмәт күрсәтү, технология, продукт, тикшеренү нәтиҗәсе) яңалык элементларының булуы | 1 - 5 | 10 | 10 - 50 |
| 2 критерий. Әлеге проектның (продукт, технология, хезмәт күрсәтү) актуальлеге һәм социаль әһәмияте | 1 - 5 | 10 | 10 - 50 |
| 3 критерий. Хезмәт нәтиҗәләрен гамәлгә кертү актлары һәм бәяләмәләр булу | 1 - 5 | 10 | 10 - 50 |
| 4 критерий. Тикшеренүнең тулылыгы һәм тирәнлеге: проектның, алгоритмның эшкәртелгәнлеге, программа продуктының көйләнгәнлеге | 1 - 5 | 15 | 15 - 75 |
| 5 критерий. Проектны тәкъдим итү. Исәпкә алына: материалны белү дәрәҗәсе, карала торган мәсьәләләрнең мәгънәсен аңлау, материалны бәян итү һәм сорауларга җавап бирү осталыгы | 1 - 5 | 15 | 15 - 75 |

Экспертлар советы әгъзасы һәр критерий буенча 1-5 балл куярга хокуклы. Балларны критерий зурлыгына тапкырлаудан килеп чыккан нәтиҗәләр һәр критерий буенча кушыла. Килеп чыккан сумма проект буенча йомгаклау баллы булып тора һәм экспертлар бәяләмәсе сыйфатында кабул ителә.

Экспертлар советының уртача арифметик бәяләмәсе проектның төп бәяләмәсен билгели.

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының 2016 елның
26 апрелендәге под-773/16
номерлы боерыгы белән
расланды

**«МӘГАРИФТӘ ИННОВАЦИЯЛӘР» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӨЧЕН ИҢ ЯХШЫ ИЛЛЕ ИННОВАЦИОН ИДЕЯ» КОНКУРСЫНЫҢ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ СОСТАВЫ**

| N | ФИО | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Фәттахов Э.Н. | оештыру комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| 2. | Поминов А.И. | оештыру комитеты рәисе урынбасары, ТатарстанРеспубликасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| 3. | Мотыйгуллин Д.Н. | оештыру комитеты сәркатибе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни-техник сәясәт бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе, Конкурста катнашуга заявкаларны кертү мөмкинлеген билгеләү буенча Оештыру комитетының эш төркеме (алга таба – эш төркеме) әгъзасы |
| 4. | Вәлиәхметов Р.Р. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни учреждениеләр эшчәнлеген җайга салу секторы әйдәп баручы киңәшчесе, эш төркеме әгъзасы |
| 5. | Гатиятуллина Г.Ф. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| 6. | Гусев С.Н. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни-техник сәясәт бүлеге башлыгы, эш төркеме әгъзасы |
| Оештыру комитеты әгъзалары | | |
| 7. | Габидуллин Д.Д. | А.Н. Туполев ис. Казан илкүләм тикшеренү-техник университетының вузга кадәр белем бирү идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| 8. | Гафуров И.Р. | Татарстан Республикасы югары уку йортларының Ректорлар советы рәисе, Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры (килешенү буенча) |
| 9. | Җәләлова Д.Г. | «Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренең Директорлар советы» коммерциясез |

| | | |
|---|---|---|
| | | партнерлыгы рәисе, Казан педагогия көллияте директоры (килешенү буенча) |
| 10. | Ногъманова Л.Н. | Казан (Идел буе) федераль университетының ректор киңәшчесе, Вузга кадәр, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры (килешенү буенча) |
| 11. | Овсиенко Л.В. | Казан илкүләм тикшеренү технологик университетының өзлексез белем бирү проректоры (килешенү буенча) |
| 12. | Савва Д.В. | «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциясез оешмасының инновацион эшчәнлекне үстерү бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| 13. | Сөләйманов Д.Ш. | академик, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Гамәли семиотика институты директоры (килешенү буенча) |

---